# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
(IV чакырылыш)

**IV чакырылышның чираттан тыш утырыш**
**КАРАРЫ**

**№10** **Акбаш ав.** **30 апрель 2025 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен
карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итү тәртибе һәм
вакытлары турындагы Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Советының
2023 елның 24 июлендәге 13 санлы карары белән расланган
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2006 елның 2 маендагы «Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы 59-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында»гы 16-ТРЗ санлы татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Советының 2023 елның 24 июлендәге 13 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итү тәртибе һәм сроклары турындагы нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гражданның мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә аның иминлеге гарантияләре

5.1. Күрсәтелгән органнарның яки вазыйфаи затның эшчәнлеген тәнкыйтьләп җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка мөрәҗәгать иткәнгә йә үз хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен йә башка затларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау максатларында гражданны эзәрлекләү тыела.

5.2. Мөрәҗәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне, шулай ук гражданның хосусый тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка тарату рөхсәт ителми. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгать җибәрү мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне тарату булып тормый.

5.3. Гражданнарның иминлеген тәэмин итү максатларында аларның оператив-эзләү эшчәнлеген яисә Россия Федерациясенең иминлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга, күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларына Эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, иминлекне тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, Тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, дәүләт саклавы өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан

мөрәҗәгатьләрне электрон документ рәвешендә җибәрүнең һәм мөрәҗәгатьләргә җаваплар, хәбәрнамәләр җибәрүнең махсус тәртибе билгеләнергә мөмкин.»;

1.2. Нигезләмәнең 6 бүлегендәге 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать 2006 елның 2 маендагы «Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы 59-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан мәҗбүри тәртиптә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта) күрсәтә, шулай ук электрон почта адресын күрсәтә йә шәхси Кабинетының адресын (уникаль идентификаторын) бердәм порталда яисә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының гражданны идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне тәэмин итүче башка мәгълүмат системасында куллана, алар буенча җавап, хәбәрнамә җибәрелергә тиеш мөрәҗәгатьне адреслаштыру турында. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә теркәргә хокуклы.»;

1.3. Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына, аны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
“Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Советының 2025 елның “30” апрелендәге 10 санлы карарына кушымта

ГРАЖДАННАРНЫ ШӘХСӘН КАБУЛ ИТҮНЕҢ ____ САНЛЫ ИСӘП КАРТОЧКАСЫ

Кабул итү көне «____»_______________ 20_____ел

Кабул итү вакыты ______ сәг. ______ мин.

Кабул итү урыны: ________________________________________________

Кабул итүне алып барган вазыйфаи затның Ф.И.А.: ____________________________

Ошема вәкиле гражданинының Ф.И.А. ______________________________
________________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны адресы һәм телефоны ______________________
________________________________________________________________________

Эш шөгыле һәм эшләү урыны ________________________________________________

Кабул итүнең кабатлануы: әйе, юк___________________________________________

Мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге____________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Йөкләмә (кемгә)________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Үтәү вакытлары, озайту турындагы белешмәләр __________________________________

Имза_________________________________________________________________

Телдән җавапка риза (әйе, юк)______________________________________

*Мөрәҗәгатьне карау максатларында минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә, саклауга һәм икенче берәүләргә җибәрүгә риза*

Имза __________________

Гаризаны карау нәтиҗәләре _______________________________________________

Контрольдән алынды «_____»__________________ 20______ел